**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№10903**
**10.11.2023**

Шәһәр һөнәри осталык
конкурсы үткәрү турында

Башкарма комитетының 2022 елның 19 октябрендәге 5650 номерлы карары белән расланган 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын үтәү йөзеннән, сәнгать белеме бирү системасының кадрлар потенциалын саклау һәм үстерү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары, концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында «Осталык та, илһам да» шәһәр һөнәри осталык конкурсын (алга таба – конкурс) 2023 елның ноябре-декабрендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 150 000 (бер йөз илле мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2023 елның 10 ноябрендәге
10903 номерлы карарына
1 нче кушымта

Өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары,
концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында
«Осталык та, илһам да»
шәһәр һөнәри осталык конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Осталык та, илһам да» һөнәри осталык конкурсы (алга таба – конкурс) Башкарма комитетның мәдәният идарәсе һәм мәдәният хезмәткәрләре профсоюзларының шәһәр комитеты тарафыннан өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары, концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында сәнгать белеме бирү системасының кадрлар потенциалына ярдәм күрсәтү максатында үткәрелә.

2. Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Яр Чаллы шәһәре хезмәт базарында өстәмә белем бирү оешмалары укытучыларының конкурентлык сәләтен арттыру;

2) укытучылар, концертмейстерлар һәм җитәкчеләрнең квалификациясен күтәрүгә булышлык итү, аларның иҗади активлыгын арттыру;

3) социаль статусны күтәрү һәм педагог һөнәре турында уңай җәмәгать фикере формалаштыру.

2 бүлек. Конкурсны оештыру

3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

4. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсның бурычларын һәм үткәрү тәртибен аңлата;

2) конкурста катнашучылардан заявкалар һәм материаллар кабул итә;

3) жюри составын формалаштыра һәм аның функцияләрен билгели;

4) конкурсның этапларын үткәрү графигын төзи;

5) конкурс документларын алып бара;

6) бүләкләү церемониясен оештыра.

5. Конкурс өч турда үткәрелә:

1) сайлап алу – урында өстәмә белем бирү оешмаларында үтә;

2) читтән торып – оештыру комитеты катнашучыларның заявка материалларын дистанцион форматта карап тикшерә;

3) йомгаклау – урындагы форматта, жюри әгъзалары конкурста катнашучылар арасында блиц-турнир үткәрә.

6. Турлар нәтиҗәләре буенча Гала-концерт үткәрелә.

7. Конкурс номинацияләре:

-«Иң яхшы укытучы»;

-«Иң яхшы концертмейстер»;

-«Иң яхшы җитәкче».

8. Конкурсның «Иң яхшы укытучы» һәм «Иң яхшы концертмейстер» номинацияләрендә Башкарма комитетның мәдәният идарәсе карамагындагы өстәмә белем

бирү оешмаларының төп хезмәткәрләре булган, урта-махсус яки югары белемгә ия укытучылар һәм концертмейстерлар катнаша ала. Катнашучыларның яше һәм стажы чикләнми.

9. Конкурсның «Иң яхшы җитәкче» номинациясендә Башкарма комитетның мәдәният идарәсе карамагындагы өстәмә белем бирү оешмаларының югары белемгә ия җитәкчеләре (директорлар һәм укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары) катнаша ала. Катнашучыларның яше һәм стажы чикләнми.

10. Конкурсның «Иң яхшы укытучы» һәм «Иң яхшы концертмейстер» номинацияләрендә катнашучылар конкурсның читтән торып үткәрелә торган турында катнашу өчен, Mail.ru саклагычында яисә видеохостинг платформасында түбәндәге материалларны урнаштыралар:

1) визит карточкасы белән видео (5 минуттан артык түгел) – төшерү өзлексез, монтажсыз алып барылырга тиеш;

2) ачык дәрес (35 минуттан артык түгел) – төшерү өзлексез, монтажсыз алып барылырга тиеш.

11. Конкурсның «Иң яхшы җитәкче» номинациясендә катнашучылар конкурсның читтән торып үткәрелә торган турында катнашу өчен, Mail.ru саклагычында яисә видеохостинг платформасында түбәндәге материалларны урнаштыралар:

1) визит карточкасы белән видео (5 минуттан артык түгел) – төшерү өзлексез, монтажсыз алып барылырга тиеш;

2) эш тәҗрибәсе күрсәтелгән видео – (30 минуттан артык түгел) – төшерү өзлексез, монтажсыз алып барылырга тиеш.

12. Конкурста катнашучылар 10 һәм 11 пунктларда күрсәтелгән заявка материалларын Mail.ru саклагычында яисә видеохостинг платформасында урнаштыралар. Урнаштырылган материалларга сылтамалар «Осталык та, илһам да» конкурсы» тамгасы белән 2023 елның 24 ноябренә кадәр оештыру комитетының электрон адресына muzshkola5@yandex.ru җибәрелә.

13. Конкурсның йомгаклау туры урында үтә торган форматта Яр Чаллы шәһәре, Строители бульвары, 9 йортта урнашкан «5 нче балалар музыка мәктәбе» МАӨББУда узачак. Үткәрү көне һәм вакыты турында катнашучыларга шәхсән хәбәр ителәчәк.

14. Конкурсның йомгаклау турында катнашучылар жюри әгъзалары өчен түбәндәге материаллар булган папка тапшырырга тиеш:

1) конкурста катнашучының соңгы 3 ел дәвамында һөнәри үсешенең мөһим этапларының тасвирламасы белән җитәкченең язмача тәкъдиме (оешмада 3 елдан ким эшләгән очракта, әлеге оешмада эшләгән барлык чор өчен). Тәкъдимнең күләме басма текстның 1 битеннән артмаска тиеш;

2) конкурста катнашучының ирекле формадагы анкетасы;

3) соңгы өч елда алган диплом һәм грамоталарның күчермәләре;

4) конкурста катнашучының һөнәри осталыгын характерлый торган башка материаллар (методик кулланмалар, вакытлы басмаларда, брошюраларда басылып чыккан чара сценарийлары, афишалар һ.б. – соңгы 3 елда).

Оешма җитәкчесенең тәкъдим итүе «Иң яхшы укытучы» һәм «Иң яхшы концертмейстер» номинацияләрендә катнашучылар өчен генә.

15. Конкурсның йомгаклау туры түбәндәге биремнәрне үз эченә ала:

1) барлык катнашучылар өчен блиц-турнир – «сорау-җавап» форматы;

2) концертмейстерлар өчен өстәмә – эш тәҗрибәсен күрсәтү (соло башкару (яттан сөйләү), кәгазьдән уку.

16. Бәяләү критерийлары:

1) «Иң яхшы укытучы» номинациясендә катнашучылар өчен – компетентлык, белем бирү методикасын белү, нәтиҗәлелек, инновациялелек, креативлык, авторлык стиле, коммуникабельлек, дөрес сөйләм, артистлык, эрудиция, куркынычсызлык һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен белү;

2) «Иң яхшы концертмейстер» номинациясендә катнашучылар өчен – башкару осталыгы, текстны белү, тамаша ясый белү, эмоциональлек, эрудиция, ансамбль техникасына ия булу, төрле уен коралларында уйнау үзенчәлекләрен белү, куркынычсызлык һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен белү;

3) «Иң яхшы җитәкче» номинациясендә катнашучылар өчен – компетентлык, оешма эшчәнлегенә җәлеп ителү, нәтиҗәлелек, инновациялелек, креативлык, коммуникабельлек, дөрес сөйләм, эрудиция, куркынычсызлык һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен белү, шәхси һәм һөнәри сыйфатларның чагылышы.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

17. Конкурска йомгак конкурс биремнәре балларын кушу нигезендә ясала.

18. Конкурсның жюри әгъзалары 10 баллы система буенча билге куялар.

Билгеләр куелганнан соң уртача балл чыгарыла һәм номинацияләр буенча җиңүчеләр билгеләнә (сәнгать төрләре буенча бүлмичә).

Конкурста «Гран-При» җюри бертавыштан 10 балл куйган катнашучыга бирелә.

«I дәрәҗә лауреат» исеме 9,5 тән 9,9 га кадәр балл җыйган катнашучыларга бирелә;

«II дәрәҗә лауреат» исеме 9,0 дән 9,4 кә кадәр балл җыйган катнашучыларга бирелә;

«III дәрәҗә лауреат» исеме 8,5 тән 8,9 га кадәр балл җыйган катнашучыларга бирелә.

IV, V дәрәҗә дипломнар бирелми.

19. Гран-При ияләре һәм I, II, III дәрәҗә лауреатлар дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнә:

1) «Гран-При» һәм «I дәрәҗә лауреат» – 15 000 сум күләмендә;

2) «II дәрәҗә лауреат» – 12 000 сум күләмендә;

3) «III дәрәҗә лауреат» – 8 000 сум күләмендә.

20. Җюри шулай ук конкурста катнашучыларны махсус дипломнар белән билгеләп үтәргә мөмкин.

21. Бүләкләү церемониясе конкурсның Гала-концертында үткәрелә.

22. Жюри беренче, икенче, өченче урыннарны бирмәү хокукына ия.

23. Жюри әгъзалары үз оешмаларының әлеге конкурста катнашучы педагогик хезмәткәрләренең чыгышларын бәяләргә, шулай ук конкурс нәтиҗәләрен алар рәсми игълан ителгәнче әйтергә хокуклы түгел.

24. Бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндә жюри рәисенең бер өстәмә тавышы бар.

25. Жюри карары катгый булып тора һәм яңадан каралырга тиеш түгел.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева